**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.12.2022 Балык Бистәсе штп. № 366пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 28.12.2020 №294пи карары белән расланган «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы балаларына һәм яшьләренә патриотик тәрбия бирү» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы яшьләр министрлыгының “Муниципаль программаларны актуальләштерү турында"гы 03.11.2022 №5507/исх-РС хаты нигезендә, муниципаль норматив хокукый актларны Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге законнарына туры китерү максатларында КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 28.12.2020 №294пи карары белән расланган «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы балаларына һәм яшьләренә патриотик тәрбия бирү» муниципаль программасын түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) программа паспортының «Программаны эшләү өчен нигезләр» пункты түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырырга:

-«Россия Федерациясендә яшьләр сәясәте турында»30.12.2020 № 489-ФЗ Федераль закон;

-«Татарстан Республикасында яшьләр һәм дәүләт яшьләр сәясәте турында» 19.10.1993 ел, №1983-XII Татарстан Республикасы Законы;

-«Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» Россия Федерациясе Президентының 04.02.2021 ел, №68 Указы;

- «Мәгариф» милли проектының «Социаль активлык», «Патриотик тәрбия» Федераль проектлары;

1.2) " Программа бурычлары» пунктын түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән

тулыландырырга:

"- патриотик тәрбия инфраструктурасын камилләштерү;

- гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү;

- "Яшьармия» Бөтенроссия иҗтимагый хәрби-патриотик хәрәкәте штабының Региональ бүлекчәсен үстерү.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.К. Вафинага йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын башкаручы Р.Л. Исланов